# КАРАР

2022 елның 18 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Беренче Май авылында узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 17 ноябрендә үткән гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча:

“Сез Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Беренче Май поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән,укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Беренче Май поселогында 1 Май урамына вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

-чишмә территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

-Беренче Май авылында юлларны кардан чистарту (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);”

« РИЗА» "КАРШЫ"

Гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 16 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 10 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" дип гражданнар җыенында катнашучы 10 кеше тавыш бирде;

«юк» дип гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1.Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Беренче Май авылында узган гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – кабул ителгән дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлегенең Беренче Май поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән,укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм

аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 2023 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүне һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүне расларга карар иттек:

- Беренче Май поселогында 1 Май урамына вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

-чишмә территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

-Беренче Май авылында юлларны кардан чистарту (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

Карар кабул ителгән дип расларга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ятмас- Дусай
авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Гарифуллина